**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 апрель № 198

г. Казань

Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 8 апрель, 198 нче
карары белән расланды

Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип дәүләт унитар предприятиеләренә, дәүләт учреждениеләренә беркетелмәгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеше аның устав капиталының 100 процентын тәшкил иткән акционерлык җәмгыятенең 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган очракта хуҗалык җәмгыяте (алга таба – хуҗалык җәмгыяте) белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыру механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы исеменнән хуҗалык җәмгыяте белән идарә итүче югары орган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра (алга таба – вәкаләтле орган).

3. Вәкаләтле орган хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышын үткәрү көненә кадәр кимендә 20 көн алдан хуҗалык җәмгыяте эшчәнлеге тармагында идарәне гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына (алга таба – тармак орган) хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышын үткәрү көне, урыны һәм үткәрү вакыты хакында хәбәр итәргә тиеш. Вәкаләтле орган җәмгыять акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышын үткәрү көнен, урынын һәм үткәрү вакытын билгели.

4. Хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышы компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр вәкаләтле органга хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышын үткәрү көненә кадәр кимендә 10 көн алдан тармак орган тарафыннан җибәрелә.

Әгәр тармак орган билгеләнгән вакытта вәкаләтле органга тәкъдимнәр җибәрмәгән очракта, хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышы вәкаләтле орган әзерләгән мәсьәләләрне карап тикшерә.

5. Тармак орган вәкилләре хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышында катнашырга һәм хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышының көн тәртибендәге мәсьәләләр хакында фикер алышуда катнашырга хокуклы.

6. Хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышы карарын, тармак орган әзерләгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, вәкаләтле

орган кабул итә һәм хуҗалык җәмгыяте акционерларының (катнашучыларның) гомуми җыелышы үткәрелгән көннән соң өч көн эчендә вәкаләтле орган боерыгы белән рәсмиләштерелә.